# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“25” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 25 ноябрендә «Сез 2022 елда Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- урам юлларындагы чокырларны ямау (вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү)

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;

3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:

- авыл территориясен чистарту,хезмәт өчен түләү,

4. Җирлектәге торак пунктларны беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү :

- электр белән тәэмин итүнең автоном резерв чыганагын сатып алу (380 В бензогенератор)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаларны башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 185(бер йөз сиксән биш) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 107 (бер йөз җиде ) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 107(бер йөз җиде) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

“Сез 2022 елда Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1.Җирле әһәмияттәге юлларга хезмәт күрсәтү:

- урам юлларындагы чокырларны ямау (вак таш сатып алу, җәю һәм транспорт хезмәтләре өчен түләү)

2. Урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү:

- лампалар,автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, хезмәтләр өчен түләү;
3. Җирлек территориясен төзекләндерү һәм чистарту:
- авыл территориясен чистарту,хезмәт өчен түләү,
4. Җирлектәге торак пунктларны беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү :
- электр белән тәэмин итүнең автоном резерв чыганагын сатып алу (380 В бензогенератор)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаларны башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Күңгәр авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче,
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Сибгатуллин Д.Р.